УДК 37.013

# ТАТАР ЭТНОПЕДАГОГИКАСЫ ҺӘМ АНА ТЕЛЕ

***Г.Т. Хәйруллин***

*«Туран» университеты*
*Алматы, Казакъстан Республикасы*
*griftim@mail.ru*

Һәр халык үзенең тарихи үсеше барышында билгеле бер тәрбия системасын булдыра. Халык тәрбиясенең тарихы һәм теориясе турындагы фәнне этнопедагогика дип атыйлар. Халык тәрбиясенең төп максаты билгеле бер шәхси сыйфатларга ия булган камил кеше тәрбияләүдән гыйбарәт. Бу сыйфатлар шулай ук дөнья диннәрендә дә карала. Халык тәрбиясе туган телдән башка мөмкин түгел. Һәр халыкның теле – бар кешелекнең мәдәни казанышы һәм аерым халыкның яшәеше өчен мәҗбүри булган төп шартларның иң әһәмиятлесе.

**Төп төшенчәләр:** халык, халык тәрбиясе, этнопедагогика, камил шәхес, туган тел

Кешелек дөньясының барлыкка килүе һәм алдагы үсеше, беренче чиратта, тупланган тормыш тәҗрибәсен киләсе буыннарга җиткерү белән бәйле. Үзенең тарихи үсеш юлында һәрбер халык[1] гасырлар буенча тикшерелгән кыйммәтләрен саклый, камилләштерә һәм яңа буыннарга тапшыра. Мондый кыйммәтләр системасына шушы халыкның матди, рухи һәм социаль эшчәнлеге барышында тупланган, дөреслеге тәҗрибә нәтиҗәләре белән дәлилләнгән фактик мәгълүматлар керә. Әгәр мәдәниятне «табигать булмаган бөтен нәрсә,... инсаниятның эшчәнлеге нәтиҗәсе» [5, б. 198] формасында кабул итсәк, әйтелгән кыйммәтләр системасын шушы халыкның мәдәнияте компоненты дип танырга була.

Халыкның рухи мәдәниятендә төп урынны тәрбия тәҗрибәсе, ягъни нәкъ шушы халыкка хас булган, шушы халык туплаган тәрбия алымнары һәм ысуллары биләп тора. Шулай итеп, халыкның рухи мәдәнияте нигезен халык тәрбиясе тәшкил итә. «Һәрбер халыкның да мәдәнияте чиксез һәм уникаль. Һәрбер этнос мохитендә меңәр еллар дәвамында үзенчәлекле дөньяга караш, традицион шөгыльләр, тормыш тәртибе, этика һәм әхлак нормалары, сәнгать, милли ашлар һәм халык медицинасы формалашкан. [...] Тарихтан безгә билгеле булган катаклизмнарда хәзерге халыклар исән

[1] Әлеге мәкалә кысаларында «халык» һәм «милләт» сүзләре синоним буларак кулланыла; милләт сүзе этник мәгънәдә генә кулланыла.

калган икән, биредә акыллы халык тәрбиясенең дә тәэсире, һичшиксез,булган дияргә мөмкин»[2, б. 12]. Бу исә һәрбер халыкның да үз педагогикасы – халык педагогикасы бар, дигән сүз (татар халык педагогикасы, рус халык педагогикасы, казакъ халык педагогикасы һ.б.). Халык педагогикасы нәкъ шушы халыкның әхлакый кануннарында һәм гореф-гадәтләрендә чагыла, аның үзе кабул иткән традицияләрен ныгыта. Халык педагогикасы байлыклары буыннан-буынга тапшырыла, тормышта куллану барышында камилләштерелә. Әлбәттә, халык тәрбиясе таләпләренә шушы халыкның этнопсихологик үзенчәлекләре дә тәэсир итә.

Халыкның тәрбия өлкәсендә тупланган тәҗрибәсен, гаилә һәм милли кыйммәтләр хакындагы әхлакый һәм нәфасәти (эстетик) карашларын өйрәнүче гыйлем тармагын этнопедагогика (этник педагогика) дип атау кабул ителгән. Этнопедагогика билгеле кысаларда социаль процессларга анализ ясый, халык тәрбиясенең эчтәлеген һәм ысулларын, аның милли-мәдәни традицияләр белән бәйләнешен өйрәнә, халыкның укыту-тәрбия тәҗрибәсен бүгенге шартларда куллану юлларын ачыклый һ.б.ш. «Гомумән һәм тулаем алганда, этнопедагогиканы халык тәрбиясенең (табигый, көндәлек, формаль булмаган, мәктәптән тыш, традицион тәрбиянең) тарихы һәм теориясе дип күзалларга булыр иде» [3, б. 5]. Башкачарак әйткәндә, этнопедагогика – халыкның тәрбия мәдәнияте турындагы фән ул.

Һәрбер халыкның тәрбия мәдәнияте (этнопедагогик мәдәният) шушы халыкның яшәеше һәм эшчәнлеге тәҗрибәсенә нигезләнә, рухи һәм матди мәдәниятенең балаларга бәйләнеше булган иң мөһим компонентларында – балалар бәйрәмнәрендә, уенчыкларында, җырларында, уеннарында, фольклорында һ.б.ш. чагыла. Этнопедагогик мәдәният шушы халыкның тарихи үсеш юлына, аның ана теленә игътибарны һәм ихтирамны күз алдында тота. Билгеле ки, халык үзенең тарихына никадәр игътибарлы булса, аның мәдәнияте дә шулкадәр югарырак була. «Үткәннәргә ихтирам – укымышлылыкны кыргыйлыктан аерып торучы сызык менә шуннан гыйбарәт» (А.С. Пушкин).

Шунысын да әйтергә кирәк, халык педагогикасы, этнопедагогика төшенчәләренең үзара нисбәте хакында башкача карашлар да бар. Мисал өчен, милли педагогика дигән төшенчә карала, ул – «тормышта, тәрбия барышында сыналган, буыннан-буынга күчеп камилләшкән, милләт тарафыннан киң кулланылган тәҗрибәгә нигезләнгән укыту-тәрбия турындагы эмпирик гыйлемнәр җыелмасы. Анда милләтнең даими кулланган тәрбия алымнары, чаралары, ысуллары, чыганаклары, тәрбияви карашлары, идеал һәм максатлары барысы бергә туплана» [7, б. 6]. Бу очракта халык педагогикасы һәм этник педагогика синонимнар буларак кабул ителәләр. «Буыннан-буынга килгән һәм баетылган тәрбия процессында кулланылган ысуллар, нәтиҗәле алымнар, гомуми кабул ителгән һәм гадәткә кергән таләпләр, гореф-гадәтләр, гыйлем, күнекмәләр, педагогик карашлар һәм бәяләр җыелмасы,тәрбия максаты, идеалы, халыкның авыз иҗаты халык

педагогикасын тәшкил итә. Аны, кыска гына итеп, этник педагогика дип тә атыйлар» [7, б. 15–16].

Бу мәкалә кысаларында кулланылган төшенчәләрне үзара чагыштыру, аларның эчтәлегенә чагыштырмалы анализ ясау максаты куелмады. Шуның өчен файдаланылган төшенчәләрнең эчтәлегенә карата башка төрле фикерләрнең дә булганлыгын күрсәтү белән чикләнәбез.

Халык тәрбиясе мәдәниятенең үзәгендә камил шәхес образы – шушы халыкның күмәк тәҗрибәсе нигезендә төзелгән, һәрбер кеше дә шуңа омтылырга тиешле булган эталон, үрнәк ята. Тәрбиянең максаты итеп шундый шәхесне формалаштыру күз алдында тотыла ки, ул камилләшкән, яки идеаль шәхескә (идеалга) куела торган барлык таләпләргә дә җавап бирергә тиеш. Монда «идеаль» дигән сүз менә шушы халыкның нәкъ хәзерге яшәеш дәверендәге күз карашларына туры килә, дигәнне аңлата. Һәрбер халыкның да шәхесне формалаштыру, аны камилләштерү өлкәсендә үзенчәлекле тәрбия мәдәнияте бар. «Камил кеше формалаштыру – халык тәрбиясенең лейтмотивы... Камиллек төшенчәсе үзе кешелек прогрессы белән бергә тарихи эволюциягә дучар булды... Шәхеснең аһәңле камиллеге идеясе кешенең үзенең табигатендә һәм аның эшчәнлеге характерында урын алган»[3, б 48]. Шулай итеп, камил шәхескә – идеаль кешегә хас булган төп сыйфатлар системасы дәверләр үзгәрү белән үзгәрешләр кичерә, ләкин бу үзгәрешләр шактый акрын, сизелер-сизелмәс кенә бара. Мисал өчен, кыргый җәнлекләрне эзәрлекли белү, кулга төшерү – борынгы заманнардан алып гасырлар дәвамында камил кешенең төп сыйфатларының берсе саналган. Хәзерге заманда исә камил шәхескә мондый таләпләр куелмый.

Әлбәттә, камил шәхеснең сыйфатлары системасының акрынлап үзгәрә баруы, беренче нәүбәттә, хезмәт төрләренең үзгәрүе һәм катлаулануына бәйле. Хезмәт төрләренең катлаулануы белән бергә кеше үзе дә үзгәрергә, яңа шартларга җавап бирерлек дәрәҗәдә үсеш алырга, камилләшергә мәҗбүр була: элегрәк оста, камилләшкән кешенең генә кулыннан килә торган эш бүген гадәти бер шөгыльгә әйләнә бит. Димәк, уңышлы хезмәт итәр өчен, хәзерге заман кешеләре белән нәтиҗәле аралашу һәм хезмәттәшлекне оештыру өчен башка төрле сыйфатлар зарур була. Шуңа күрә, камил шәхес – ул фикер йөртә белүче кеше, инициативалы һәм үзенең үсеше өстендә эшли белүче кеше. Үзен-үзе камилләштерүгә сәләт – кешенең иң зур рухи байлыкларына карый. Халык авыз иҗатына мөрәҗәгать итсәк, анда тасвирланган камил кешенең һәрвакытта яңа шартларны исәпкә ала белүче, таныш булмаган очракларда да уңышлы алымнарны таба алучы, куелган максатына ирешер өчен көрәшергә сәләтле булуын күрербез.

Камил кешенең шәхси сыйфатлары тупламын шартлы рәвештә өч төркемгә бүлеп карау урынлы булыр. Хәзерге заман халыкларының иң зур күпчелегенә хас булган сыйфатларны гомумкешелек кыйммәтләре дип атарга була. Камил шәхеснең мондый сыйфатларына чибәрлек,

сәламәтлек, ихтыяр көче, кыенлыкларны җиңеп чыга алу сәләте, сабырлык, чыдамлылык, үз иленңне һәм халкыңны сөю һ.б.ш. сыйфатлар кирә. Кайбер сыйфатлар аерым халыклар төркемендә киң танылган. Мисал өчен, Урта Азия халыкларында өч хәерле сыйфат мактала: яхшы ният, мәрхәмәтле сүз, игелекле хәрәкәт; тау яки дала кешеләре исә камил кеше сыйфатлары арасында беренче урынга кунакчыллыкны куялар.

Кайбер сыйфатлар системасы тик бер генә халыкның камил кешегә куя торган таләпләренә карый. Яшәеш һәм хезмәт шартларының төрле булуы, географик һәм табигать шартларының, шулай ук тарихи үсеш процессының күптөрле булуы нәтиҗәсендә һәрбер халык та камил шәхеснең төп сыйфатларына үзенең таләпләрен формалаштырган. Теге яки бу таләпләрнең үзенчәлекле булуы шушы халыкның алдынгы яки артта калган икәнен дәлилләми. Һәр халык нәкъ үзенең тарихи юлын үткән, бу юл яхшырак та, начаррак та түгел, тик башка юл. Шуңа күрә камил шәхес сыйфатларында да, тәрбия эшләрендә дә һәр халыкның башкалардан аермалы яклары, үзенчәлекләре чагылыш таба. «Тарихи һәм тарихи булмаган халыклар, шулай ук педагогик иҗатка сәләтле һәм сәләтсез халыклар юк. Камил шәхесне тәрбияләүне аңлы рәвештә кайгырту барлык халыкларга да хас – зурларына да, кечкенәләренә дә» [3, б. 52].

Шулай итеп, һәрбер халыкның да үзенә генә хас камил кеше образы бар, менә шул образ халык тәрбиясенең нигезендә ята. Мисал өчен, бурят халык тәрбиясендә камил ир кешедән тугыз төрле гыйлем таләп итәлә: аучы – эзләүче осталыгы, төз ата белү, җәя бавын киерә белү, сигезле камчыны үрү осталыгы, тиредән ат тышавын әзерләү осталыгы, металл белән эшләү һөнәренә ия булу, милли көрәштә осталык, чабыш атын тәрбияли белү, сөякне бер сугуда сындыра белү. Казакъ халык тәрбиясендә камил ир заты (чын егет) бөркет кебек елгыр, лачын кебек горур, арыслан кебек дәһшәтле, юлбарыс кебек көчле, бүре кебек кыю, каплан кебек куркыныч, дөя кебек чыдамлы, ат кебек сизгер, поши кебек куәтле һ.б.ш. сыйфатларга ия булырга тиеш. Чын егет игътибарлы, оста, кыю, көчле, хәрәкәтчән була, аның күркәм сыйфатларына намуслылык, гаделлек, хаклык кирә [8, б. 35–36].

Татар халык педагогикасында да камил шәхес (чын кеше, ир егет) тәрбияләү мәсьәләсе үзәк урынны биләп тора. «Һәр милләтнең, шул исәптән татарларның да, иң изге, мәңгелек педагогик хыялы – һәрьяктан камил шәхес тәрбияләү» [7, б. 17]. Чын татар кешесе дөреслеккә омтыла һәм аны таный ала; кыю була; туган иленә, халкына, үзенең сүзләренә турылыклы була; ул үзенең хаталарын таный белә һәм аларны төзәтергә сәләтле; үзенең бурычын вакытында һәм кирәкле сыйфатта үтәргә булдыклы; гадел, намуслы һәм чыдамлы; ышанычлы, тапкыр һәм кыю һ.б.ш. Камил татар кешесенә ят булган сыйфатлар арасына кансызлык, вәхшилек, комсызлык, тупаслык, булдыксызлык һ.б.ш. сыйфатлар бар. Халык авыз иҗатында (дастаннарда, риваятьләрдә, әкиятләрдә, мәкальләрдә, әйтемнәрдә, җырларда, бәетләрдә, такмакларда һ.б.) камил кешене

характерлый торган, яки аңа ят булган сыйфатлар ачылган һәм аларга тиешле бәя бирелгән.

Камил татар кешесенә хас булган иң мөһим сыйфатларның берсе хезмәткә мөнәсәбәтне чагылдыра. Чын кеше хезмәт сөюче, оста һөнәр иясе булырга тиеш. Бу фикер байтак әкиятләрдә, күп санлы халык мәкальләрендә дә чагылыш таба. «Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз», «Эшләгәнең кеше өчен, өйрәнгәнең үзең өчен», «Һөнәрле кол үлмәс», «Идел кичми ил булмас, эш белмәгән ир булмас» һ.б.ш. мәкальләрдә эшкә өйрәнү алга куелса, башка мәкальләрдә хезмәт белән бәйле икенче сыйфатларга игътибар ителә: «Тырышкан табар – ташка кадак кагар», «Агач җимеше белән, адәм эше белән», «Бер яхшы эш мең яхшы сүздән артыграк», «Иренмәгән иртәгәге эшен бүген бетергән» һ.б.

Халык авыз иҗатында урын алган «Иренгән ике эшләр» хикәятендә ялкаулык тәнкыйть ителә. Ата кеше һәм улы юлларында бер дагага тап булалар. Малай арбадан төшеп даганы алырга иренә. Атасы иренми, даганы ала, аны базарда сата, шуның акчасына алма сатып ала. Кире кайтканда ата кеше бер алманы юлга ташлый. Алмага бик кызыккан малай арбадан төшә дә, алманы алып ашый. Әтисе шул рәвешле малайны кабат-кабат йөгертә. Арбадан бер тапкыр төшеп, даганы алырга иренгән малайга берничә мәртәбә төшәргә туры килә. Шулай итеп, «Иренгән ике эшләр» дигән мәкальнең мәгънәсе ачыла, ялкаулыкка кире бәя бирелә.

Камил татар кешесе хатын-кызга, анага чиксез ихтирам белән карый. «Оҗмах аналарның аяк астында», «Ана арыслан баласы өчен утка кергән», «Ханнан бала олы, баладан ана олы», «Анаң өчен уч төбендә тәбә куырсаң да бурычыңны кайтара алмассың» дип юкка гына әйтмәгән бит халык. Чын татар кешесе атасын да олылый белә: «Ата аркасы – кала аркасы», «Атаң кебек кешегә тел озайтма», «Атаңа ни кылсаң, алдыңа шул килер» һ.б.

Камил кешенең сыйфатлары системасында танылган кагыйдәләргә буйсынуга, башка кешеләр арасында үзеңне тота белүгә, башкаларга ихтирамлы булуга, кешеләр белән дөрес аралашуга карата ачык таләпләр куела. Чын кеше башкаларны тыңлый һәм аңлый, киңәшләшә белергә, үзара аралашу кагыйдәләренә һичшиксез буйсынырга сәләтле булырга тиеш. «Сыйлаганда су эч», «Аз сөйлә, күп тыңла», «Киңәшле эш таркалмас», «Таш белән атканга да аш белән ат», «Яхшылыкка яхшылык – һәр кешенең эшедер, яманлыкка яхшылык – ир кешенең эшедер» ди татар халкы.

Чын татар кешесе гыйлемгә омтыла. Татар халык әкиятләренең төп герое үзенең белеменә таянып барлык киртәләрне уңышлы үтә, дошманнарын җиңә. Мәкальләрдә кешенең белемлелеге югары куела, белемгә омтылу күркәм сыйфат итеп бәяләнә: «Көчле кеше берне егар, белемле кеше меңне егар», «Белем һәр куркынычны җиңәр», «Гыйлем дәрәҗәсе иң югары дәрәҗә», «Җирнең нуры – кояш, кешенең нуры – гыйлем». Кайбер мәкальләр турыдан-туры белем алырга өнди: «Җиде йортның телен бел, җиде төрле белем бел», «Бәхетне юлдан эзләмә, белемнән эзлә», «Галим булсаң, галәм синеке» һ.б.

Камил татар кешесенә куелган таләпларнең байтагы ислам диненең таләпләренә туры килә. Белем алуга, гыйлемгә өндәү, мисал өчен, хәдисләрдә китерелгән түбәндәге сүзләрдә ачык күренә: «Галим бул, галим булалмасаң, галимнең укучысы бул, белемле кешеләрне күбрәк тыңла», «Белем алыр өчен кирәк булса, ерак Кытайга кадәр бар, чөнки белем алу мөселманга фарыз», «Бәхетле булуга бердәнбер чара – укымышлы булу» һ.б.

Ислам дине мөселманнарны шәфкатьле булырга, рәхимлелеккә, үзара килешеп яшәргә, башкаларга ихтирамлы булырга, кичерә белергә, сабырлыкка өнди. Ислам террор һәм көчләүгә каршы чыга, кемне дә булса ирексезләп ислам динен кабул итүгә мәҗбүрләү катгый тыела. Кешеләрне рәнҗетмәскә, ялган ант итмәскә, гайбәт таратмаска, яхшы ниятләр, изге фикерләр, таза күңел белән яшәргә, үзеңнең эшләреңөчен җаваплы булырга – болар барысы да чын мөселман кешесеннән таләп ителә. Явызлык, мактанчыклык, әдәпсезлек һ.б.ш. тискәре сыйфатлар мөселманнарда булмаска тиеш. Өлкәннәргә һәм бигрәк тә ата-анага ихтирамсыз булу мөселман динендәге кеше өчен иң зур гөнаһлардан исәпләнә. Мөхәммәд Пәйгамбәр күрсәткәнчә, әгәр кем дә булса ялган сөйли, биргән вәгъдәсен үтәми, үзенә ышанган кешегә хыянәт итә икән, ул кешенең, гәрчә ураза тотса да, гыйбадәт кылса да, өлкән хаҗ яки кече хаҗ кылса да, үзен мөселман дип әйтүе ялган булыр [6, б. 215].

Мөселманнарга карата куелган шушы таләпләр камил татар шәхесенә куелган таләпләр системасында да урын алган.

Шуны да әйтергә кирәк, камил шәхеснең байтак сыйфатлары исламда гына түгел, христиан динендә дә, буддизмда да чагыла. Моңа мисал итеп «Кеше үтермә», «Урлашма», «Хыянәт итмә» кебек таләпләрне китерергә мөмкин. Мөхәммәд Пәйгамбәр, Христос, Будда һәм башка Пәйгамбәрләр кешеләрне намуслы һәм әдәпле булырга өнди, шулай булмаганда Ходай исеменнән куркыныч җәза белән яный.

Халык тәрбиясе, камил шәхесне формалаштыру, тәрбиянең халыкчанлыгы – болар барысы да ана теленә барып тоташа. Бөек рус педагогы К.Д. Ушинский (1824–1870) әйткәнчә, «Халыкның теле югала икән – халык үзе юк инде». Ана теленә ихтирам белән карау, аны саклау һәм үстерү – һәр миллә вәкиленең изге бурычы, милләтнең дә үзаңы үсеше дәрәҗәсен күрсәтүче мөһим критерий. «Тел – милләтнең тарихи, иҗтимагый, сәяси үзгәрешләр басымы астында югалмыйча сакланып калуын күрсәткән төп факторларның берсе» [6, б. 75]. Димәк, татар халык тәрбиясе, татар этнопедагогикасы турында уйлыйбыз икән, беренче чиратта татар телен саклау мәсьәләсен хәл итәргә кирәк. Шулай булмаганда, татар халкының да, аның бай матди һәм рухи мирасының да тарихта эзе генә калачак.

Россия империясендә рус булмаган һәм бигрәк тә славян булмаган халыклар күп гасырлар дәвамында милли тигезсезлек басымы астында гомер кичерделәр. Дәүләтнең рәсми тарихында бу хәл бик ачык күренә. Шул искиткеч зур территориядә бөек мәдәният ияләре булып тик Киев кенәзлеге,

Мәскәү кенәзлеге һәм аларның варислары гына исәпләнә иде. Бу тезис мәңгелек тарихи дөреслек итеп кабул ителде, шуңа күрә аның турында шөбһәләнү мөмкин түгел иде. Славян булмаган халыклар корган дәүләтләр искә алынса, алар тик тискәре яктан гына тасвирланды, алдынгы тыныч рус дәүләтенең мәкерле дошманнары итеп күрсәтелде. Тыныч кына яшәгән күршеләренә каршы Россиянең канлы яулап алу сугышлары тарихи гаделлек, прогрессив процесс дип кабул ителде. Башка халыкларның ролен түбәнәйтү хисабына славян элементының тарихи ролен чиксез күпертү – бөекрус шовинизмын ныгыту факторына әйләнде. Әлбәттә, мәсьәлә бу бөек халыкның теге яки бу яхшы яки тискәре сыйфатларында түгел.

Күптән узган тарихи вакыйгаларга тискәре караш борынгы халыкларның бүгенге варисларына күчерелде. Бу җәһәттән бигрәк тә татарларга кыен туры килде. Тарихи әдәбият, бөтенләй диярлек, шул «кыргый халыкка» карата каргышка тулган. Бу әдәбият киң таратыла торды, мәктәпләрдә өйрәнелде. Болар барысы да рус булмаган халыкларның ана телен кимсетүгә китерде. Россия, СССРның күп кенә халык вәкилләренең аңында үзенең туган теленә, тарихына, диненә карата тискәре мөнәсәбәт тәрбияләнде.

Советлар хакимлегенең беренче ике дистә ел дәвамындагы гомере татарлар өчен аларның уку-яза белүен юкка чыгару белән бәйләнгән. Чынлап та, 20 нче елларда гарәп графикасыннан латин язуына күчү – бөтен халыкны укый да, яза да белмәгән шәхесләр көтүенә әйләндерде. Латин хәрефләрен белгән яшүсмерләр буынын үстереп бетерүгә, тагын яңа «революция» килеп чыкты – кириллицага күчү башланды. Бу хәл тагын тулысынча наданлык, китапларны юкка чыгару һ.б.ш. юлдаш күренешләрне алып килде. Шул ук елларда киң колач җәйгән дингә каршы көрәш гарәп графикасы нигезендә язылган, анда-монда калган китапларның да башына җитте. Татар теленең кулланыш даирәсе кимегәннән-кими барды. Идел буе, Себер өлкәләрендәге татар мәктәпләре, техникумнары ябыла башлады, Татарстанның авыл җирләрендә дә укыту эшен русчага күчерә башладылар. «Тарихи бердәмлек – бөек совет халкы» өчен рус булмаган милләтләрнең ана телләренең бертөрле әһәмияте дә юк иде; туган телләрне куллану мәйданы көннән-көн тарая килде. «Бөек совет халкы» бары тик бөек телдә – рус телендә генә сөйләшергә тиеш булгандыр.

Яңа Россиянең беренче елларында Татарстан җитәкчеләре һәм татар әдипләре татар телен торгызу, саклау һәм үстерү өлкәсендә байтак уңышларга ирештеләр. Татар язучылары, шагыйрьләре ана телендәге әсәрләре белән укучыларны куандырдылар. Танылган татар җырчылары халыкның җыр сәнгатен саклау һәм үстерүгә үз өлешләрен керттеләр. Бөтен дөньяга таралып яшәгән татарларны берләштерүгә кирәкле игътибар бирелде. Бу өлкәдә Бөтендөнья татар конгрессы да зур роль уйнады.

Ләкин хәзергесе көндә татар теле яңа кысуларга дучар булып, кызганыч хәлгә кала башлады. Ана теле бүгенгесе көндә нигездә авылларда гына калып бара, монысы да вакытлыча гына, чөнки татар авыллары

мәктәпләрендә дә укыту рус теленә күчерелә бара. Россия мәктәпләрендә дәүләт имтиханнарын бары тик рус телендә генә тапшыру таләбе куелу татар мәктәпләренең саны кимегәннән-кими баруга, татар телендә югары белем алу мөмкинлеге юкка чыгуга китерде. Шулай итеп, балаларны ана телендә укыту даирәсе елдан-ел тарая бара. Татарстаннан читтә яшәүче биш миллион татар өчен бер генә телеканал эшли (ТНВ-Планета), аның да материаллары соңгы вакытта яртылаш диярлек рус теленә күчерелде. Татар теле һич бер дәлилсез чүпләндерелә, бу телнең үз сүзләре башка тел сүзләре белән бер нигезсез кысырыклап чыгарыла. Татарларның шактый өлеше бүгенге көндә үзенең туган телен белми. Шулай итеп, ана теленең эреп бетү процессы һәм, димәк, милләтнең югалу куркынычы алга килеп басты.

Республика хакимиятендә проблеманың нидәрәҗәдә җитди икәнлеген аңласалар да, кирәкле чаралар күрелми, чөнки бу өлкәгә караган тәкъдимнәр Россия Федерациясе хөкүмәте тарафыннан читкә кагыла. Дөрес, Россия Федерациясе Президенты В.В. Путин 2002 елда Бөтендөнья татар конгрессы делегатлары белән очрашканда бу мәсьәләгә үзенең карашын ачык аңлаткан иде: «Әгәр күпмилләтле илдә кем булса да туган телне тыя икән, яки шуңа киртә куя икән, бу тулысынча тинтәклек һәм саташу. Бу бөтенләй мөмкин хәл түгел һәм тулаем алганда илгә зыянлы. Россия – шундый милли, мәдәни һәм тел байлыгының тупланмасы ки, мондый байлык дөньяда башка бер җирдә дә юк. Безнең мәмләкәтнең көче нәкъ менә шунда». Ләкин бу сүзләр түрәләргә барып җитмәде.

Әйтергә кирәк, хәзерге замандагы зур мәмләкәтләр күпмилләтле һәм аларда милләтара мөнәсәбәтләр мәсьәләсен хәл итү өчен нигезле дәүләт сәясәте юлга салынган. Милли мәнфәгатьләрне канәгатьләндерү төрле юллар белән хәл ителә. Мисал өчен, Австриядә милли азчылык эшләре буенча федераль министрлык эшли, Даниядә – Гренландия буенча министрлык, Италиядә регионнар хезмәте, Финляндиядә – саамнар эше буенча Совет, чегәннәр буенча Совет оештырылган һ.б.

Халыкларның милли мәнфәгатьләрен канәгатьләндерү юлында туган телләрне саклауга зур игътибар бирелә, милли телләргә хәстәрле караш кабул ителгән. Әйтик, Швейцариядә дүрт дәүләт теле кулланыла, кечкенә генә Сингапурда исә дәүләт телләре саны бишкә җитә. Нинди дә булса милләт вәкилләре берәр өлкәдә тупланып яшәсә, байтак илләрдә аларның туган теле мәктәпләрдә мәҗбүри өйрәтелә. Финляндия судларында гражданнар туган телләрендә эш йөртергә хокуклы, судья фин һәм швед телләрен белергә тиеш (монда халыкның алты процентын шведлар тәшкил итә).

Росиянең җан күршесе, казакъларның тарихи ватаны булган Казакъстан Республикасын алыйк. Монда 130 дан артык милләт вәкиле көн күрә, аларың этномәдәни мәнфәгатьләрен канәгатьләндерүгә игътибар ителә. Казакъстан Президенты Н.А. Назарбаев төрле халыкларның телләрен, мәдәниятен саклау хакында түбәндәгеләрне ассызыклап әйтә: «Менә шуны онытырга ярамый: Казакъстан – чын мәгънәсендә күпмилләтле дәүләт... безнең өчен иң мөһим мәсьәлә – Казакъстанда яшәүче бөтен

халыкларның да, алар никадәр генә «кечкенә» яки «зур» булса да, милли-мәдәни кыйммәтләрен саклау. Аларның һәрберсенең дә үз тамырлары, үзләренең бөек ата-бабалары, бай тарихлары бар, без боларның кадерен белергә тиешбез» [4, б. 262]. Аннан соң: «Халыкларны унификацияләүгә, ассимиляцияләүгә һәм бер халыкны башка халыклар тарафыннан бастырырга маташуга, милли кыйммәтләргә һәм телләргә ихтирамсыз булуга киләчәктә урын юк» [4, б. 370–371]. Шулай итеп, Казакъстан җирлегенә берничә гасыр элек кенә килеп утырган халыкларның телләренә, милли мәдәниятләренә ихтирам күрсәтелә.

Туган телләргә булган мөнәсәбәт, һичшиксез, милли тәрбиягә дә йогынты ясый. Чөнки һәр кеше, бигрәк тә бала, башкалар тарафыннан үзенең ана теленә булган карашны тоя, һәм бу тойгы аның үз милләтенә, аның тарихына, кыйммәтләренә һ.б. мөнәсәбәте формалашуга тәэсир итә. Татарларның тарихи ватаны булган регионда шушы халыкның ана теленә карата ихтирам нинди дәрәҗәдә икәнлеген Татарстан мисалында карыйк. Бу төбәктә татар теленә карата мөнәсәбәт географик атамалардан ук күренеп тора, монда татар атамаларына мыскыллы караш һәр адымда чагыла. Билгеле булуынча, мондый атамалар тәрҗемә ителергә тиеш түгел, бары тик сүзләрнең әйтелеше генә башка телләрнең фонетикасына якынлаштырыла. Мисал өчен, Тувадагы Кызыл шәһәре рус язмаларында Красное (Красновск, Красино һ.б.ш.) формасында бирелүе мөмкин дә түгел. Америкадагы Нью-Йорк шәһәрен дә Новый Йорк дип язмыйлар. Әмма Татарстанда Югары, Иске һ.б.ш. сүзләрне тәрҗемә итү практикага кергән. Шуның нәтиҗәсендә яртылаш татарчага охшаш, яртылаш русча яңа атамалар барлыкка килә. Берничә мисал гына китерик: Олы Елга авылы Татарстанда – Большие Елги, Югары Байлар – Верхний Байлар, Иске Кадермәт – Старое Кадерметьево, Юеш Күрнәле – Мокрые Курнали, Яңа Мусабай – Новый Мусабай, Кыр Шынталысы – Степная Шентала, Чирүле Шонталы – Служилая Шентала, Базарлы Матак – Базарные Матаки, Урманасты Үтәмеш – Подлесный Утямыш, Югары Чәке – Верхнее Чекурское һ.б.ш. Мондый ясалма руслаштырылуны берничек тә аңлатып булмый, чөнки монда экономия дә юк (атамаларның татарча язылуы бу яктан караганда файдалырак); Олы, Иске, Яңа, Түбән, Югары кебек сүзләрне дә рус теле фонетикасына якынлаштырып әйтеп була. Ике сүздән гыйбарәт булган авыл исемнәрен тулысынча рус теленә тәрҗемә иткән очраклар да бар бит әле: Новое Дрожжаное (Яңа Чүпрәле), Черное Озеро (Кара Күл) һ.б.

Экономиягә килсәк, нигездә татар атамасын калдырганда да, ясалма русчалаштыруның файдасын табу кыен. Әйтик, авыл исеме булган Таулар сүзе рус теленең фонетикасына туры килә, аны ни өчен Тавларово дип атау кирәк булганлыгы аңлашылмый. Шундый ук атамалар исәбенә Балтач – Балтаси, Кармыш – Карамышево, Кайбыч – Кайбицы, Иштирәк – Иштиряково, Ишки – Ишкеево, Шахмай – Шахмайкино сүзләрен дә һ.б.ш. кушарга була.

Кайбер очракта татарча исемнең тәрҗемәсе төп исемгә якын да килми. Мисал өчен, Җәйләү – Евлеево, Чыпчык – Чепчуги, Колын – Колуново, Муллаиле – Молвино. Мондый мисалларның саны да җитәрлек.

Гаделлек өчен шуны да өстәргә кирәк. Кайбер очракларда географик атамаларның рус телендә язылуы бөтен дөньяда килешенгән тәртипләр нигезендә хәл ителгән. Мондый сүзләрдә татар теле дә, бу сүзнең төп чыгышы да дөрес чагыла: Узяк (Үзәк), Таллы Буляк (Таллы Бүләк), Иске Юрт (Иске Йорт), Суюндук (Сөендек), Тиган Буляк (Тигән Бүләк), Ак Чишма (Ак Чишмә), Таллы-Куль (Таллы Күл), Суык-Чишма (Суык Чишмә), Яшельча (Яшелчә). Алай гына да түгел, аерым атамалар һич үзгәртелмичә рус телендә кулланыла: Акбаш, Якты Юл, Кызыл Ялан, Карамалы, Наратлык, Каенлык, Камышлы, Чиялетау. Болай булгач, татар теленә зыян китермичә дә, аның гүзәллеген сакларга омтылып та географик атамаларны кулланырга була икән. Шушы телгә ихтирамлы мөнәсәбәт беркемгә дә зыян китерми, эштә, үзара аралашуда кыенлык та өстәми икән.

Димәк, татар телен ихтирам итү, аны саклау мәсьәләсе татарларның үзләренә, аларның ана теленә карата булган мөнәсәбәтләренә бәйле икән. Халык үзе туган теленә битараф карагач, бу очракта ана телен саклап калу мөмкинчелегенә өметләнү нигезсездер. Халык үзе дә ихтирам итмәгән телне башка халыклар да сакламый икән, моңа аптырарга кирәкми.

Казакъ халкының бөекулы Абай Кунанбаев (1845–1904) кайчандыр татарларның үз динен, гореф-гадәтләрен саклауларына, тырышлыгына соклануын түбәндәге сүзләр белән аңлаткан иде: «Татарларга карасам, солдат хезмәтенә дә чыдый, ярлылыкка да түзә, бәла-казага да бирешми; муллаларны, мәктәпләрне саклап, динне дә тота. Эшләп мал табуның да җаен шулар белә, зиннәт, купшылык та шуларда [...] Алар бер-берсе белән ызгышып хурланмастан, хуҗалык белән шөгыльләнә, һөнәргә өйрәнеп, мал таба белә – менә шуларның нәтиҗәсе ул» [1, б. 142]. Димәк, татарлар ул вакытларда үзенең татарлыгын да, телен дә, гореф-гадәтләрен дә саклый белгән икән ләбаса.

Галимнәрнең раславынча, дөньяда алты меңнән артык тел исәпләнсә, һәр айда ике тел юкка чыгып бара икән. Россия халыкларының 177 теленнән тик берсенә – рус теленә генә дәүләт законы тарафыннан саклану гарантиясе бирелгән. «Гарантиясез» калган телләр арасында татар теле дә бар. Димәк, татар теленең саклану-сакланмавы, беренче нәүбәттә, татарларның үз кулларында. Киләчәктә милләтем яшәсен, дигән татар ана телен саклауның хәстәрен күрергә бурычлы, бүгенгесе көндә ана теле халыкның кичектергесез ярдәменә мохтаҗ.

Йомгаклап әйткәндә, татар халык тәрбиясе – буыннан-буынга тапшырылып килгән милли байлык, ә татар этнопедагогикасы – педагогика фәннәренең билгеле бер тармагы. Боларның киләчәге дә, татар халкының үзенең киләчәге дә, аның саклануы да ана теленең язмышына бәйле.

## ӘДӘБИЯТ

1. Абай. Кара сөз. Поэмалар. Книга слов. Поэмы. Алматы, 1993. 272 с.
2. Ахияров К.Ш. Народная педагогика и современная школа. Уфа, 2000. 328 с.
3. Волков Г.Н. Этнопедагогика. М., 1999. 168 с.
4. Назарбаев Н.А. Сборник докладов на 1–10 сессиях Ассамблеи народов Казахстана. Астана, 2005. 439 с.
5. Набок И.Л. Педагогика межнационального общения. М., 2010. 304 с.
6. Түрік тілді халықтар тарихындағы Ғабдолла Тоқайдың орны: халықаралық ғылыми-тәжірибелік конференция материалдары. Орал (Уральск), 2013.
7. Шәймәрданов Р.Х., Хуҗиәхмәтов Ә.Н. Татар милли педагогикасы. Казан, 2007. 399 б.
8. Этнопедагогика народов Казахстана. Алматы, 2001. 305 с.

**Автор турында белешмә:** Хәйруллин Гриф Тимерзаһит улы – педагогика фәннәре докторы, профессор, «Туран» университеты (050013, Сатпаев ур., 16–18, Алматы шәһәре, Казакъстан Республикасы); griftim@mail.ru

## ТАТАРСКАЯ ЭТНОПЕДАГОГИКА И РОДНОЙ ЯЗЫК

***Г.Т. Хайруллин***

*Университет «Туран»*
*Алматы, Республика Казахстан*
*griftim@mail.ru*

Каждый народ в процессе своего исторического развития создает определенную систему народного воспитания. Науку об истории и теории народного воспитания называют этнопедагогикой. Центральная идея народного воспитания – формирование совершенного человека, обладающего системой определенных личностных качеств. Подобные качества рассматриваются также и в мировых религиях. Народное воспитание невозможно без родного языка. Язык любого народа – это культурное достояние всего человечества и необходимое условие существования самого народа.

**Ключевые слова:** народ, народное воспитание, этнопедагогика, совершенная личность, родной язык

**Сведения об авторе:** Хайруллин Гриф Тимурзагитович – доктор педагогических наук, профессор, Университет «Туран» (050013, ул. Сатпаева, 16–18, Алматы, Республика Казахстан); griftim@mail.ru

## TATAR ETHNOPEDAGOGY AND NATIVE LANGUAGE

***G.T. Khayrullin***
*«Turan» University*
*Almaty, Republic of Kazakhstan*
*griftim@mail.ru*

Every nation in the process of historical development creates a certain system of national education. The study of the history and theory of national education is called ethnopedagogy. The central idea of national education is the formation of the ideal human personality within a system of certain personal characteristics. This article discusses the characteristics of the ideal person in Tatar ethnopedagogy. These characteristics are compared to similar ideal images of the human personality with morals prevalent in Islam and other world religions.

National education is impossible without use of native languages. The language of any nation represents all humankind's cultural heritage and a necessary condition for the existence of the nation for whom it is considered native. The author considers the ideal human personality as manifested in Tatar language, folklore, and literature. He also examines the role of the Tatar language in the development of national education and the importance of native languages for education. He analyzes the language policies of several multinational states, including the Russian Federation and Kazakhstan, with regards to preserving of minority languages.

**Keywords:** ethnopedagogy, ideal human personality, national education, native language, Tatars

REFERENCES

1. Abay. Kara søz. *Poemalar. Kniga slov. Poemy* [The Book of Words. Poems]. Almaty, 1993. 272 p.
2. Akhiyarov K.Sh. *Narodnaya pedagogika i sovremennaya shkola* [National Pedagogy and the Contemporary School]. Ufa, 2000. 328 p.
3. Volkov G.N. Etnopedagogika [Ethnopedagogy]. Moscow, 1999. 168 p.
4. Nazarbaev N.A. Sbornik dokladov na 1–10 sessiyakh Assamblei narodov Kazakhstana [A Collection of Reports at Sessions 1–10 of the Assembly of Peoples of Kazakhstan]. Astana, 2005. 439 p.
5. Nabok I.L. *Pedagogika mezhnatsional'nogo obshcheniya* [The Pedagogy of Inter-Ethnic Communication]. Moscow, 2010. 304 p.
6. *Turik tildi halyktar tarihyndagy Gabdolla Tokajdyn orny: halykaralyk gylymi-tazhiribelik konferencija materialdary* [Gabdulla Tukay's Place in the History of the Turkic-Speaking Peoples: Materials from an International Scientific Practical Conference]. Oral (Ural'sk), 2013.
7. Shajmardanov R.H., Khuziakhmetov A.N. *Tatar milli pedagogikasy* [Tatar National Pedagogy]. Kazan, 2007. 399 p.
8. Etnopedagogika narodov Kazakhstana [Ethnopedagogy of the Peoples of Kazakhstan]. Almaty, 2001. 305 p.

**About the author:** Grif T. Khayrullin – Doctor of Science (Pedagogy), Professor, «Turan» University (16–18, Satpayev st., Almaty 050013, Republic of Kazakhstan); griftim@mail.ru